ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КОРГУЗИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
КАРАГУЖА АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

07.11.2019 — с. Коргуза — 53

## Югары Ослан муниципаль районының Карагуҗа авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю Тәртибе турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Югары Ослан муниципаль районының Карагуҗа авыл җирлеге Уставы нигезендә, 2019 елның 5 ноябрендәге 1 нче номерлы гражданнар җыенында кабул ителгән карарны гамәлгә ашыру максатларында, Карагуҗа авыл җирлеге Башкарма комитеты карар бирде:

1. Югары Ослан муниципаль районының Карагуҗа авыл җирлеге Патрикеево авылында үзара салым акчаларын җыю тәртибен расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм җирлекнең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземә калдырам.

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районының
Карагуҗа авыл җирлеге башлыгы — С.А.Сакин

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районының
Карагуҗа авыл җирлеге
Башкарма комитетының 2019 елның
7 ноябрендәге 53 номерлы карарына
1 нче кушымта

Югары Ослан муниципаль районының Патрикеево авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю Тәртибе

1. Әлеге Тәртип Югары Ослан муниципаль районы Карагуҗа авыл җирлегенең Патрикеево авылындагы үзара салым акчасын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Гражданнарның үзара салым акчасын түләү гражданнар җыенында катнашуларына бәйсез рәвештә, Югары Ослан муниципаль районының Карагуҗа авыл җирлеге территориясендә теркәлгән 18 яшькә җиткән гражданнар һәм алар тавыш биргәндә белдерелгән мөнәсәбәтләргә бәйле рәвештә 2020 елның 1 гыйнварыннан 2020 елның 31 мартына кадәр гамәлгә ашырыла.

3. Түбәндәге категория гражданнар үзара салым акчаларын түләүдән азат ителә:

а) Бөек Ватан сугышында катнашучылар.

Аерым категория гражданнар өчен:

а) 1 төркем инвалидлар,

б) Бөек Ватан сугышы ветераннары

түләү күләме гражданнар җыены турындагы карарда билгеләнгән сумманың 50 процентын тәшкил итә.

4. Бер тапкыр түләү турында хәбәр итү (хәбәрнамә) бланкы имза яки почта элемтәсе аша юллау юлы белән гражданнарга җиткерелә.

Хәбәрнамәдә (хәбәр итү) гражданнарның үзара салым акчаларын күчерүнең түләү реквизитлары, тулы яки киметелгән күләмдә бер тапкыр түләү суммасы, аны түләү срогы булырга тиеш.

5. Гражданнарның үзара салымыннан алынган акчалар Югары Ослан муниципаль районы Карагуҗа авыл җирлеге Башкарма комитетының шәхси счетына керә.

6. Гражданнар тарафыннан түләүләр физик затлар йөкләмәсе буенча исәп-хисапларны гамәлгә ашыру хокукына ия булган оешмалар (исәп-хисап оешмалары) аша почта күчерүе аша яки Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталы аша башкарыла( https://uslugi.tatarstan.ru/).

7. Керем касса ордеры, чек-ордер квитанциясе, түләү фактын раслаучы башка документлар түләү фактын раслый.

8. Билгеләнгән вакытка кертелмәгән үзара салым акчалары законнарда билгеләнгән тәртиптә түләттерелә.